ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 февраль 2026ел № 1867

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2019 елның 29 мартындагы 1625 номерлы Карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе турында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2019 елның 29 мартындагы 1625 номерлы Карары (Башкарма комитетның 2020 елның 22 октябрендәге 5445 номерлы, 2023 елның 3 апрелендәге 2602 номерлы Карарлары редакциясендә) кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Шатлык» ЯҮ МАУ тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр:

- ата-аналары махсус хәрби операция зонасында булган балалар өчен, махсус хәрби операциядә катнашканда яралану сәбәпле дәваланууда булган граждан-хәрби хезмәткәрләрнең балалары өчен, махсус хәрби операциядә катнашу чорында алган хәрби травмалар яки авырулар нәтиҗәсендә 1 төркем инвалид булган граждан-хәрби хезмәткәрләрнең балалары өчен; ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен бушлай күрсәтелә;

- күп балалы гаиләләрдәге балалар өчен, сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле балалар өчен, хәрби хәрәкәтләр ветераннарының балалары өчен 50 процент күләмендә ташлама белән күрсәтелә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов